## 17. Сандугач

Сандугачым,моңлы кошым,
Тыңлыймын кичен-иртән.
Сандугачның бу җырлары,
Нидән соң дәртле икән?
Кушымта: Сандугачым,сандугачым,
Әй, моңлы сайрар кошым.
Былбыллы туган җиремдә
Үтсә иде язмышым.
Күңелең җырлап торганда,
Син үзең дә сандугач.
Бәхеткә күмелеп яшисең,
Янда якыннар булгач.
Кушымта.
Аларның дәртле авазын,
Яратамын тыңларга.
Мин дә куңел җырларымны,
Багышлыйм якыннарга.